КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 июнь г.Казань № 610

Татарстан Республикасында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт учреждениеләрендә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 3 өлеше, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $13^{1}$ статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт учреждениеләрендә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрен расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин